Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VI-2**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 19 декабре

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 41 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 29 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне яңа редакциядә расларга (алга таба – Нигезләмә).
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2011 елның 18 августындагы IX-2 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.
3. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгына Нигезләмәне дәүләт теркәвенә алуны башкару буенча вәкаләт бирергә.
4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Л Ислановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының 2020
елның 19 декабрендәге
VI-2 номерлы карары белән
расланды

**“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Бүлек) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге карамагына кертелгән вәкаләтләр чикләрендә дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыручы һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы, яшьләр сәясәте һәм спорт объектларын популярлаштыручы органы булып тора. Шулай ук Татарстан Республикасы тарафыннан федераль законнар нигезендә тапшырылган дәүләт вәкаләтләре чикләрендә.

Бүлекнең оештыру-хокукый рәвеше – муниципаль казна учреждениесе.

1.2. Бүлекнең рус телендәге тулы аталышы – Муниципальное казенное учреждение «Отдел по молодежной политике, спорту и туризму Исполнительного комитета Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан».

Рус телендәге кыскартылган аталышы – МКУ «Отдел по молодежной политике, спорту и туризму».

1.3. Бүлекнең татар телендәге тулы аталышы – Татарстан Республикасы Балык бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе.

Татар телендәге кыскартылган аталышы – “Яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе.

1.4. Бүлекнең оештыручысы (гамәлгә куючысы) – Балык Бистәсе муниципаль район Советы, Бүлеккә беркетелгән мөлкәт милекчесе (хуҗасы) – “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль район).

1.5. Бүлек физик культура, спорт һәм туризмны үстерү һәм районның яшьләр оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә муниципаль идарә функцияләрен тормышка ашыра.

1.6. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларына, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм

боерыкларына (күрсәтмәләренә), бүтән норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.7. Бүлек юридик зат булып тора, үз исеменнән мөлкәти һәм мөлкәти булмаган хокукларны сатып ала һәм гамәлгә ашыра, вазыйфаларын үти, судларда дәгъвачы, җавап бирүче һәм өченче зат була ала, муниципаль район гербы сурәтләнгән һәм үз аталышы булган мөһер һәм бланкка, үз эшчәнлеге өчен кирәкле булган бүтән мөһерләргә, штампларга, бланкларга, законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган тиешле бюджет һәм башка счетларга ия.

1.8. Бүлек эшчәнлеген финанслау әлеге максатларга бүлеп бирелгән ассигнованиеләр чикләрендә, шулай ук федераль законнар нигезендә муниципаль районга бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен республика бюджетыннан субвенцияләр рәвешендә бүлеп бирелә торган средстволар исәбеннән муниципаль район бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

1.9. Бүлекнең ведомство буйсынуындагы (карамагындагы) учреждениеләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Дельфин”спорт-сәламәтләндерү комплексы” муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесе;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җәмәгать тәртибен саклау буенча “Форпост” яшьләр (студентлар) берләшмәләре үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе;

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Сәйлән” балалар сәламәтләндерү лагере” муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Яшьләр үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе.

Муниципаль районның яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлегенең муниципаль бюджет учреждениеләренә бухгалтерлык хезмәт күрсәтүе Бүлек структурасына керә торган финанс-хуҗалык бүлеге аша гамәлгә ашырыла.

1.10. Бүлек аның компетенциясендә билгеләнгән чикләрдә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә әлеге Нигезләмә нигезендә эшчәнлек төрләре буенча оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

1.11. Учреждениенең урнашу урыны (юридик адресы): 422650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 83В йорт.

## 2. 2. Бүлекнең бурычлары

Бүлекнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

2.1. Яшьләр оешмалары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру һәм халыкның төрле категорияләрен физкультура, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүгә тарту;

2.2. Яшьләр сәясәте һәм физик культураны, спортны, туризмны үстерү өлкәсендә республика программаларын һәм проектларын тормышка ашыруда катнашу;

2.3. Яшьләр, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристлык иҗтимагый оешмаларына яшьләрне җәлеп итү;

2.4. Яшьләр, физкультура-савыктыру, спорт һәм туристлык оешмалары активларын һәм кадрларын әзерләүне һәм яңадан әзерләүне тәэмин итү;

2.5. Яшьләр, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристик программаларга, проектларга эксперт бәяләве үткәрү һәм аларны тормышка ашыруга ярдәм итү;

2.6. Физик культура, спорт, туризм һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны тәэмин итү;

2.7. Республика физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристлык чараларында район спортчыларын һәм командаларын әзерләү һәм аларның катнашуын оештыру;

2.8. Массакүләм спортны үстерү, спортчы-разрядчы һәм мастерлар - шәһәр, район, Татарстан Республикасы һәм Россия җыелма командаларына кандидатлар әзерләү буенча эшне оештыру;

2.9. Районда физик культураны һәм спортны үстерү планнарын эшләү, чараларны оештыру һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

2.10. Дәүләт яшьләр сәясәтен социаль-икътисадый, хокукый, оештыру шартларын һәм яшь гражданнарны социаль яктан аякка бастыру һәм үстерү гарантияләрен булдыру аркылы, аларны бөтен җәмгыять мәнфәгатьләрендә тулысынча шәхес мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру аша тормышка ашыру;

2.11. Яшьләрне төрле яклап үстерү, аны мөстәкыйль тормышка яраклаштыру, яшь гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү программаларын эшләү һәм тормышка ашыру;

2.12. Яшьләрнең иҗтимагый-сәяси активлыгын күтәрү һәм ныгыту, аны иҗтимагый-файдалы эшчәнлеккә җәлеп итү, яшьләр лидерларының мөмкинлекләрен җәмгыять мәнфәгатьләрендә эзләү, ачыклау һәм куллану, кадрлар резервын әзерләү;

2.13. Укучыларның һәм яшьләрнең рухи-әхлакый, гражданлык һәм патриотик сыйфатларын формалаштыруга юнәлдерелгән гражданлык, патриотик тәрбия системасын үстерү;

2.14. Хокукый, икътисадый һәм оештыру шартларын, аларның эшчәнлеге гарантияләрен һәм стимулларын булдыру һәм тәэмин итү максатларында яшьләр, балалар иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм итү;

2.15. Бүлек вәкаләтләре чикләрендә балаларның, яшүсмерләрнең, яшьләрнең ялга, сәламәтләндерүгә, тулы кыйммәтле ял һәм мәшгульлеккә хокукларын тәэмин итү, яшьләрнең, балаларның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм актив ялын оештыру өчен шартлар тудыру;

2.16. Яшь кешеләрдә мөһим тормыш кыйммәтләре буларак сәламәтлеккә һәм гаиләгә мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итү, катлаулы тормыш хәлләрендә консультация ярдәме оештыру, асоциаль тәртипне профилактикалау (кисәтү);

2.17. Яшь гаиләгә, талантлы яшьләргә, яшьләр берләшмәләренә ярдәм итүне гамәлгә ашыру;

2.18. Өстәмә белем бирү учреждениеләре, яшьләр өлкәсе хезмәткәрләрен методик, оештыру һәм хокукый яктан тәэмин итү.

## 3. Бүлекнең функцияләре

3. Үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә Бүлек түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Яшьләрнең ихтыяҗларын, мәнфәгатьләрен һәм аның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының социаль-икътисадый үсешендә катнашу мөмкинлекләрен, шулай ук халыкның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә ихтыяҗын анализлый;

3.2. Район, яшьләр чараларын, спорт ярышларын уздыруны тәэмин итә;

3.3. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауны гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча билгеләнгән тәртиптә агитация-пропаганда материалларын чыгаруны тәэмин итә;

3.4. Билгеләнгән тәртиптә Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына спортчыларга һәм тренерларга, физик культура хезмәткәрләренә, физкультура активистларына спорт исемнәре (званиеләре, дәрәҗәле исемнәр) бирү өчен тиешле документларны тәкъдим итә;

3.5. Физик культура, спорт һәм туризм инфраструктурасын үстерү буенча чаралар күрә;

3.6. Физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә җирле бюджетны эшләүдә катнаша;

3.7. Яшьләр, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристлык оешмалары реестрын алып бара;

3.8. Яшьләр, физкультура-савыктыру, спорт һәм туристлык оешмалары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

3.9. Район предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында яшьләр, физкультура-савыктыру, спорт һәм туристлык оешмаларының нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итүче норматив-хокукый документлар кабул итә;

3.10. Гамәлдәге законнар нигезендә бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра;

3.11. Физкультура, предприятиеләр, учреждениеләр, уку йортлары, барлык төрдәге спорт мәктәпләре коллективларының эшчәнлеген тикшереп тора.

3.12. Кызыксынган оешмалар белән берлектә эшли, физкультура-массакүләм чараларның һәм спорт ярышларының календарь планын раслый һәм аларның уздырылуын контрольдә тота;

3.13. Физик культура, спорт өлкәсендә фәнни тикшеренүләрне оештыруны һәм үткәрүне яраштыра, бу өлкәдә алдынгы тәҗрибәне һәм казанышларны баета, аларны физкультура оешмаларының эш практикасына кертүне оештыра;

3.14. Спорт һәм физик үсеш буенча исәпкә алуны, хисап бирүне алып бара, спорт төрләре буенча рекордлар һәм казанышларны раслый, спортчылар билгеләгән республика рекордларын раслау өчен билгеләнгән тәртиптә документлар тапшыра;

3.15. Җирле матбугат, радио, телевидениене әлеге максатларда файдаланып физик культураны, спортны пропагандалауны оештыра. Билгеләнгән тәртиптә плакатлар, методик кулланмалар чыгара, фотокүргәзмәләр оештыра;

3.16.Кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә спорт корылмаларын, спорт инвентаре прокаты пунктларын һәм базаларын кулланылышын исәпкә алуны һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

3.17. Билгеләнгән тәртиптә спорт разрядлары, судья категорияләре бирә, спорт ярышларында җиңүчеләрне һәм призерларны, физкультура хезмәткәрләрен, активистларны, физкультура коллективларын, спорт җәмгыятьләре һәм ведомство физкультура оешмалары советларын призлар, вымпеллар, медальләр, дипломнар, грамоталар белән бүләкли;

3.18. Яшьләр сәясәте өлкәсен үстерү тенденцияләренә комплекслы анализ һәм фаразлауны, муниципаль район территориясендә максатларны һәм бурычларны нигезләүне үткәрә;

3.19. Муниципаль районның икътисадый һәм социаль үсеш программаларын тормышка ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

3.20. Максатчан программаларны эшләүдә һәм тормышка ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

3.21. Билгеләнгән өлкәдә муниципаль район эшчәнлеге нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итә;

3.22. Мәдәни-танып белү туризмын үстерүгә ярдәм итә; мәгълүмати ярдәм күрсәтә, шулай ук җирле үзидарә органнарына, яшьләр сәясәте өлкәсе учреждениеләренә законнарны куллану мәсьәләләрендә ярдәм итә;

3.23. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру һәм тормышка ашыру өлкәсендә программалар һәм чараларны эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнаша. Аларның үтәлешенә анализ ясый;

3.24. Инициативалы яшьләргә ярдәм итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

3.25. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыра;

3.26. Балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрнең ялын, буш вакытын һәм мәшгульлеген оештыру буенча чараларны гамәлгә ашыра;

3.27. Яшьләрнең асоциаль тәртибен профилактикалау, наркоманияне, алкоголизмны һәм токсик бәйлелекнең төрле формаларын җиңүгә юнәлтелгән чаралар оештыра;

3.28. Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карары буенча төзелә торган комиссияләр эшендә катнаша;

3.29. Яшьләр оешмалары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

3.30. Башкарма хакимият органнары белән берлектә балаларның ялын оештыра һәм аларны савыктыру өчен шартлар тәэмин итә;

3.31. Яшьләр сәясәте өлкәсендә конференцияләр, киңәшмәләр, күргәзмәләр, конкурслар, фестивальләр оештыра һәм аларны үткәрүдә катнаша;

3.32. Яшьләр сәясәте өлкәсендә республика программаларын һәм проектларын тормышка ашыруда катнаша;

3.33. Яшьләр, физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм туристлык иҗтимагый оешмаларына яшьләрне тарта;

3.34. Яшьләрнең шәхси үсеше, үзлегеңнән белем алу һәм иҗади хезмәте, аларның һөнәри үзбилгеләнеше, ялы өчен оптималь шартлар тудыра;

## 4. Бүлекнең хокуклары һәм бурычлары

4.1 Бүлек хокуклы:

4.1.1.Федераль һәм республика башкарма хакимият органнарында муниципаль район Советы, район Башкарма комитетының яшьләр сәясәте һәм спорт өлкәсендәге йөкләмәсе буенча тәкъдим итәргә, үз вәкилләренең киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашуын тәэмин итәргә;

4.1.2. Үз компетенциясе чикләрендә боерык рәвешендә норматив хокукый актлар чыгарырга, барлык ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне, нигезләмәләрне, регламентларны, инструкцияләрне, методик документларны расларга;

4.1.3. Үз хокукларын яклау максатларында законнарда билгеләнгән тәртиптә суд һәм хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә;

4.1.4. Законнарда каралган тәртиптә муниципаль район бюджеты акчалары, субвенцияләр рәвешендә бүленә торган республика бюджеты акчалары белән үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, максатчан программалар белән билгеләнә торган юнәлешләр буенча эш итәргә;

4.1.5. Бүлеп бирелүче акчалар чикләрендә грантлар, стипендияләрне гамәлгә куярга;

4.1.6. Физик культура, спорт һәм туризм өлкәсендә муниципаль учреждениеләргә оператив идарәгә тапшырылган муниципаль мөлкәтне исәпкә алып, аның саклнышына контрольне гамәлгә ашырырга;

4.1.7. Бүлек компетенциясе өлкәсенә караган координацион, консультатив органнар, иҗтимагый советлар, эксперт төркемнәре, вакытлы иҗади коллективлар һәм башка шундый структуралар булдырырга һәм аларның эшендә катнашырга;

4.1.8. Бүлек вәкаләтләрен үтәү өчен зарур булган физик культура объектлары өлешенә карата кирәкле экспертизалар һәм бәяләмәләр, шулай ук фәнни тикшеренүләр оештыруда һәм үткәрүдә катнашырга;

4.1.9. Физик культура өлкәсе оешмаларыннан (оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә) аларның функцияләрен үтәү белән бәйле документларны, шулай ук Бүлек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мәгълүматларны соратырга һәм билгеләнгән тәртиптә алырга;

4.1.10. Физик культура, спорт һәм туризм эшлекләләрен билгеләнгән тәртиптә дәүләт бүләкләренә, премияләргә һәм мактаулы исемнәр бирүгә тәкъдим итү турында, оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә һәм коллективларга исемнәр, категорияләр һәм разрядлар бирү турында үтенечнамә бирергә (юлларга);

4.1.11. Ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан гамәлгә куючы биремнәренең үтәлешен, муниципаль мөлкәтне биләүнең, аннан файдалануның һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә мөлкәтнең билгеләнеше һәм сакланышы буенча файдалануны контрольдә тотарга, оператив идарә хокукында учреждениеләргә беркетелгән артык, файдаланылмый торган яки билгеләнеше (аталышы) буенча файдаланылмый торган мөлкәтне алу буенча чаралар күрергә, физик культура, спорт һәм туризм объектларын саклау һәм саклап калу өлкәсендә законнарны үтәүгә үзидарәлек контролен гамәлгә ашырырга;

4.1.12. Ведомство буйсынуындагы физик культура, спорт һәм туризм оешмаларын үзгәртеп кору, бетерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

4.1.13. Дәүләт идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм башка оешмаларга гарызнамәләр юлларга һәм Бүлеккә йөкләнгән функцияләрне үтәү өчен кирәкле икътисади, статистик, хокукый һәм башка мәгълүматны түләүсез алырга;

4.1.14. Конкурслар, ярышлар, семинарлар һәм башка спорт-гаммәви чаралар оештырырга һәм уздырырга;

4.1.15. Ярышларда катнашу өчен тренер-укытучыларны, ведомство карамагындагы учреждениеләрнең йөртүчеләре белән спортчыларны командировкаларга җибәрергә;

4.2. Муниципаль район, муниципаль район Советы, район Башкарма комитеты билгели торган башка функцияләрне гамәлгә ашырырга.

4.3. Бүлек бурычлы (тиеш):

4.3.1. Үз компетенциясе кысаларында муниципаль казна мөлкәте белән нәтиҗәле идарә итәргә, муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Советы, Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәләрен (кушканнарны) вакытында үтәргә;

4.3.2. Билгеләнгән срокларда үз эшчәнлеге турында муниципаль район Башлыгына, муниципаль район Советына, район Башкарма комитеты Җитәкчесенә хисап тапшырырга.

4.3.3. Муниципаль районда барлык оешмалардагы физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшенең торышын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

4.3.4. Бүлек утырышларында оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр, мәктәпләр, уку йортлары, спорт җәмгыятьләре советлары җитәкчеләренең физик культураны, спортны үстерү мәсьәләләре буенча хәбәрләрен, мәгълүматларын, хисапларын тыңларга;

4.3.5. Физик культура, спорт мәсьәләләре буенча хөкүмәт карарларының үтәлешен тикшерү, шәһәрдә һәм районда физик культура, спорт һәм туризм үсешенең мөһим проблемаларын, шулай ук спортны һәм туризмны үстерү бүлеге һәм башка физкультура-спорт оешмалары эшчәнлеген яхшырту мәсьәләләрен карау өчен билгеләнгән тәртиптә киңәшмә һәм активлар чакырырга;

4.3.6. Физкультура һәм спорт объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә техник-икътисадый нигезләрне, проект-смета документациясен карауда катнашырга;

4.3.7. Спорт мәсьәләләре буенча эксперт, консультация һәм мәгълүмати-аналитика советлары, комитетлар һәм комиссияләр төзергә, аларның составларын һәм алар турында Нигезләмәләрне расларга;

4.3.8. Үз компетенцияләренә кагылышлы, шул исәптән икътисадый стимуллар һәм санкцияләр куллану буенча тәкъдимнәр кертергә;

4.3.9. Физкультура һәм спорт учреждениеләрен имин эксплуатацияләүгә техник күзәтчелекне гамәлгә ашыруда катнашырга.

## 5. Бүлек мөлкәте һәм финанслары

5.1. Бүлек мөлкәте муниципаль районның муниципаль милке булып тора һәм бүлеккә оператив идарә хокукында беркетелә.

5.2. Беркетелгән мөлкәтнең составы, аның бәясен һәм биләү, файдалану һәм эш итү шартларын бәяләү ул мөлкәтне беркетү турындагы шартнамә белән, оператив идарә хокукында һәм гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

5.3. Бүлекнең мөлкәтен һәм финанс ресурсларын формалаштыру чыганаклары түбәндәгеләр:

- бюджет һәм бюджеттан тыш акчалар;
- оператив идарәгә тапшырылган муниципаль мөлкәт;
- башка дәрәҗәдәге бюджетлардан капиталь кертемнәр (взнослар) һәм дотацияләр;
- түләүсез хәйрия кертемнәре, оешмалар, учреждениеләр, гражданнар иганәләре;
- Россия Федерациясе законнары нигезендә башка чыганаклар.

5.4. Оператив идарәгә тапшырылган мөлкәт арендага бирелә яисә законнарда каралган башка хокукта беркетелә, бары тик Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты рөхсәте белән генә.

5.5. Баланста торучы мөлкәт белән оператив идарә итүне гамәлгә ашырганда Бүлек бурычлы:

- оператив идарә хокукында аңа беркетелгән мөлкәтне нәтиҗәле файдаланырга, аның сакланышын һәм максатчан файдалануны тәэмин итәргә;
- оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәтнең техник торышы (хәле) начарлануга юл куймаска; бу таләп эксплуатация барышында әлеге мөлкәтнең норматив тузуына бәйле начараюына кагылмый;
- Бүлеккә беркетелгән мөлкәтне капиталь һәм агымдагы ремонтлауны тормышка ашырырга.

5.6. Бүлеккә оператив идарәгә беркетелгән мөлкәт тулысынча да, өлешчә дә түбәндәге очракларда алынырга мөмкин:

- Россия Федерациясе законнары нигезендә бетерү һәм үзгәртеп кору турында карар кабул ителгәндә.

## 6. Бүлекнең структурасы

6.1. Балык Бистәсе муниципаль районы Бүлеге структурасына түбәндәгеләр керә:

- Бүлек Башлыгы;
- Башлык урынбасары;
- 2 баш белгеч;
- Бүлекнең әйдәүче белгече.

## 7. Бүлек эшчәнлеге белән җитәкчелек итү

7.1. Бүлекне Башлык җитәкли.

7.2. Башлыкны вазыйфага билгеләү һәм вазыйфасыннан азат итү, конкурс нәтиҗәләрен исәпкә алып, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7.3 Бүлек Башлыгы, бүлек Башлыгы урынбасары Башкарма комитет органының вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре булып тора.

7.4. Бүлек Башлыгы:

7.4.1. Бүлеккә бер генә кеше идарәсе нигезендә җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, район Башкарма комитеты җитәкчесе каравына чыгымнар сметасын, Бүлек структурасын һәм штат расписаниесен әзерли һәм тапшыра, хезмәт законнары нигезендә Бүлек хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә, Бүлек хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслый;

7.4.2. Бүлек эшчәнлеге өчен бөтен җаваплылыкны үз өстенә ала, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренең эшчәнлеген координацияли (яраштыра);

7.4.3. Бүлек исеменнән ышанычнамәдән башка эш итә, аны барлык предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә, судларда тәкъдим итә;

7.4.4. Бүлек хезмәткәрләренә кызыксындыру (мактау, бүләкләү) чараларын куллана һәм гамәлдәге законнар нигезендә дисциплинар җәза билгели;

7.4.5. Бүлек мөлкәте, финанс чаралары белән эш итә, счетларны ача һәм яба, алар буенча операцияләр башкара;

7.4.6. Бүлектә хезмәт, финанс һәм хисап дисциплинасы үтәлешен тәэмин итә;

7.4.7. ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләрен эшкә ала һәм эштән азат итә, аларга карата хезмәт законнары нигезендә дисциплинар җәза һәм кызыксындыру (бүләкләү) чараларын куллана;

7.4.8. үзенә йөкләнгән бурычларны тиешенчә гамәлгә ашыру өчен башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

7.5. Бүлек башлыгы урынбасары һәм белгечләре үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны расланган вазыйфаи инструкцияләр нигезендә башкаралар.

## 8. Мәнфәгатьләр низагын (каршылыгын) булдырмау һәм җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр низагы дигәндә вазыйфа биләүче затның мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тоткан шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яисә читләтеп) булган вазгыять аңлашыла, ул аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) тиешенчә, объектив һәм гадел башкаруына йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин.

8.2. Шәхси кызыксыну дигәндә акча, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, мөлкәти характердагы хезмәтләр, башкарылган эшләр нәтиҗәләре яисә вазыйфаи зат һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта торучы яки эшнә булган затлар (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-энеләр, апа-сеңелләр, шулай ук ир белән хатынның туганнары, ата-аналары, ир белән хатынның балалары һәм балаларының балалары), вазыйфаи зат һәм (яисә) аның белән якын туганлыкта торучы яисә эшнәлектә булган затлар мөлкәти, корпоратив яисә башка якын мөнәсәбәтләргә бәйле булган гражданнар яисә оешмалар тарафыннан нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу мөмкинлеге аңлашыла (алга таба – урындагы затның шәхси кызыксынуы белән бәйле затлар).

8.3. Бүлек башлыгы Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә мәнфәгатьләр низагы барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр низагын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш. Бүлек башлыгы эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) хезмәт бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә бурычлы. Хәбәр итү

тәртибе Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

**9. Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү, Бүлек эшчәнлеген туктату**

9.1. Бүлекне үзгәртеп кору һәм бетерү, нигезләмәгә үзгәрешләр кертү, нигезләмәне яңа редакциядә раслау муниципаль район Советы карары буенча яки башка җирле үзидарә органы тарафыннан РФ законнарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9.2. Бүлекне үзгәртеп кору Бүлекнең хокук һәм бурычларын аның хокук варисына күчүгә китерә.

9.3. Бүлекне бетергән очракта, муниципаль район Советы яисә аның турыдан-туры вәкаләтләре буенча районның башка җирле үзидарә органы ликвидация комиссиясен билгели, ул раслауга ликвидация балансын тәкъдим итә.

9.4. Әгәр гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, бүлекнең акча средстволары һәм кредиторлар белән исәп-хисап ясаганнан соң калган башка мөлкәте Бүлек милекчесенә тапшырыла.